# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пунктында 2025 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

2024 елның 29 ноябреннән №19

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пунктының Завод урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түбәндәге категория гражданнардан тыш, 2025 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертергә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
в) СВО катнашучылары гаиләләре

Аерым категория гражданнар өчен түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) 1нче төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Шилангы торак пункты чикләрендә Завод урамындагы гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров